РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«17» июня 2021 г. г. Альметьевск № 39

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү хакында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указын үтәү йөзеннән

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы, муниципаль хезмәт вазыйфаларын алып баручы гражданнар, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар үзләренең, шулай ук, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәр, мөлкәт һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 3 октябрендәге 148 номерлы карары белән расланган «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар керемнәр, мелкәт һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мелкәт турында һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру турында нигезләмә хакында» карары нигезендә, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаларын биләүче гражданнар, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының «Россия Федерациясе Президентының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла торган белешмәләр белән бергә, «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы 1 нче кушымта нигезендә, үзләре ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларына карый торган цифрлы финанс активлары һәм башка цифрлы хокуклар, утилитар цифрлы цифрлы хокуклар һәм

цифрлы валюта (алар булган очракта) турында хәбәрләр тапшыра.

2. Район Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йекләргә (Шәйхетдинова Ф.А.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов